| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 13.03.2015** **№ 64**

**«Коррупциячел гамәлләрнең куркынычлылык дәрәҗәсенә бәйле дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары Исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 369 санлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы, «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге № 230-ФЗ санлы Федераль законнарга туры китерү максатыннан,

б о е р а м:

1. «Коррупциячел гамәлләрнең куркынычлылык дәрәҗәсенә бәйле дәүләт гражданлык хезмәте вазифалары Исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2014 елның 24 ноябрендәге 369 санлы боерыгына ( алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Исемлеккә кертелгән вазифаларның берсен биләгән зат ел саен керемнәр, мөлкәтләр һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмә бирү өчен билгеләнгән вакытка, белешмәләр бирү елы ( алга таба – хисап чоры) алдыннан килгән бер календарь ел дәвамында, һәр җир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләрен, пайларын) сатып алу буенча үзе, хатыны (ире) һәм ( яисә) балигъ булмаган балалары килешү (сделка) кылганда, әгәр хисап чоры алдыннан килгән соңгы өч

ел өчен ул килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кереме суммасыннан артып китсә, үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм шул килешүләргә тотылган акча чыганаклары хакында белешмәләр бирергә бурычлы. »;

3 пунктта:

3 абзацта нокта тыныш билгесен нокталы өтер тыныш билгесе белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«эш бирүче, әлеге Боерык белән расланган Исемлеккә кертелгән дәүләт вазифасын биләгән гражданин белән әлеге Боерыкның 3 пункты 1 абзацында күрсәтелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтү) хезмәт килешүләрен яки гражданлык-хокукый килешүләрне төзегәндә, әлеге гражданин дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында, Россия Федерациясенең хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, ун көн эчендә соңгы эш урыны буенча дәүләт хезмәткәрен эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) шундый килешү төзелү хакында мәгълүмат тапшырырга бурычлы;

– эш бирүче тарафыннан әлеге Боерыкның 3 пункты 4 абзацында билгеләнгән вазифаларны үтәмәү хокук бозу булып санала һәм ул Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.».

2. Әлеге Боерыкны Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

3. Әлеге Боерык рәсми басылып чыкканнан соң ун көн узгач үз көченә керә.

4 . Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис М.Р.Зарипов